Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама бистә Советы

КАРАРЫ

20 февраль 2026 ел №16

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 212 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Түбән Мактама ш.т.б.» муниципаль берәмлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Түбән Мактама ш.т.б.» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 31, 32 бүлекләре нигезендә,

Түбән Мактама бистә Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 212 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Түбән Мактама ш.т.б.» муниципаль берәмлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә Советының 2015 елның 05 маендагы 240, 2015 елның 30 октябрендәге 11, 2018 елның 20 августындагы 129, 2019 елның 06 мендагы 155, 2021 елның 02 августындагы 31 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 пунктның 4.1 пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган салым салу объектлары, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш;»;

1.2. 3 пунктның 3.1, 3.2 пунтчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. өч һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган физик затлар (мәгариф оешмаларында көндезге бүлектә белем алучы 23 яшькә кадәрге балалар);

3.2. мәгариф оешмаларында көндезге бүлектә белем алучы балигъ булмаган балалар һәм 23 яшькә кадәрге балалар, әлеге пунктның 3.1 бүлегендә күрсәтелгән физик затлар;».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында, Әлеге карарны Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе, Некрасов ур., 18А йорты, 30А йорты, Завод ур., 2А йорты, Достоевский ур., 10 йорт, Х.Атласи ур., 1А йорты, Совет ур., 84 йорт һәм Тихоновка авылы, Терешкова ур., 34А йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтындана урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бистә җирлеге башлыгына йөкләргә.

Түбән Мактама шәһәр тибындагы
бистә башлыгы В.Н. Сенин